«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2022 елның 27 сентябре № 61

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 статьялары, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 7 статьяның 1 өлешендәге 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру»;

3) 7 статьяның 1 өлешендәге 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

4) 64 статьяның 4 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр;

5) 53 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- муниципаль һәм хосусый торак фондының торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану, барлык торак урыннары Россия Федерациясе милкендә яисә Россия Федерациясе субъекты милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш;

6) 16 статьяның 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6.1. Халык саны 3000 кешедән азрак булган җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын, шулай ук 15 депутаттан ким булган җирлекләрнең вәкиллекле органнары һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларын сайлаулар бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча уздырыла;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Куйбышев Затоны штп, Ульяновск шоссесы 12;
ТР, Кама Тамагы районы, Куйбышев Затоны штп, Куйбышев ур., 2А;
ТР, Кама Тамагы районы, Куйбышев Затоны штп, Парк ур.

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Советы рәисе Н.Б. Ефимов